КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 август г.Казань № 709

Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны оештыру турында

«Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны оештыру турында» 2019 елның 7 декабрендәге 1608 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзара хезмәттәшлеген координацияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 апреленнән 30 апреленә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә Бөтенроссия халык санын алуны үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетын Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү эшләрен координацияләү һәм оештыру өчен җаваплы Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстанстат) территориаль органына ярдәм итәргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына социаль хезмәт күрсәтү

оешмаларында, медицина оешмаларында, мәгариф оешмаларында яшәүче яки булган затларны исәпкә алуны оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары мөгаллимнәрен һәм студентларын халык турында мәгълүмат җыючы затлар сыйфатында җәлеп итүдә ярдәм итәргә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча агентлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга:

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрүне мәгълүмати яктырту;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару.

7. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль җәзаларны үтәү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә үз вәкаләтләре нигезендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләүдә һәм үткәрүдә Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстанстат) территориаль органына ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2020 елда һәм 2021 елның беренче яртыеллыгында административ-территориаль берәмлекләрне һәм муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп коруны, географик объектларның исемнәрен үзгәртүне гамәлгә ашырмаска;

Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең территориаль органына (Татарстанстат), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә аның структур бүлекчәләренә тиешле муниципаль берәмлекләр, шул исәптән шәһәр округлары һәм җирлекләр (шәһәр һәм авыл җирлекләре) территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе гражданнары турында мәгълүматлар җыюга җәлеп итүгә булышлык күрсәтергә;

2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуга кагылышлы басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар бүлеп бирергә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин